**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«26» март 2021 ел** **№ 67**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 5 октябрендәге 291 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру һәм хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2009 елның 20 маендагы 107 нче номерлы карарлар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пунктына таянып, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Россия Федерациясенең 2020 елның 09 декабрендәге 2062 нче номерлы “Заказ бирүчеләрнең сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) төрләренә карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләренә 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында” карарын үтәү йөзеннән, карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 5 октябрендәге 291 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру һәм хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында» (2009 елның 20 маендагы 107 номерлы карарлар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«7. Сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторингны, дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыруны җайга сала торган закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә, сатып алулар өлкәсендә контроль һәм

мониторинг процессында заказчылар тарафыннан әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актларның үтәлешен тикшерү гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н.Газизовка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов